ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

________16.02.2024_________ № _206_____

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районында муниципаль социаль ярдәм күрсәтү тәртибе турында» 2010 елның 23 июлендәге 1518 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районында муниципаль социаль ярдәм күрсәтү тәртибе турында» 2010 елның 23 июлендәге 1518 номерлы карарына (14.04.2016 № 608, 04.10.2016 № 1976, 29.09.2017 № 2451 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Түбәндәге эчтәлекле 2.1., 2.2 пунктлар белән тулыландырырга:

«2.1. Әлеге карар нигезендә социаль ярдәм чараларын күрсәтүче органнар Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформаны (алга таба - ЕЦЦПСС) куллану юлы белән Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕЦПСС операторы билгеләгән форматлар нигезендә социаль ярдәм чараларын бирү турында мәгълүмат тапшыруны тәэмин итәләр.

2.2. Әлеге карарда күрсәтелгән гражданнар категорияләренә социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат ЕЦЦПССтан файдалану юлы белән Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕЦЦПСС операторы билгеләгән форматлар нигезендә алынырга мөмкин.».

2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының социаль тәэмин итү өлкәсендәге аерым карарларына үзгәрешләр

кертү турында» 2017 елның 29 сентябрендәге 2451 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә.

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин